


***Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№2 Октябрь, 2025 ел*



**5 октябрь – хөрмәтле укытучыларыбызның һөнәри бәйрәме. Бәйрәмегездә Сезгә озын, сәламәт гомер, тыныч тормыш һәм эшегездә зурдан - зур уңышлар телибез.**

**Ветеран укытучылар белән танышуны дәвам итәбез**

**Фазылҗанова Рузилә Илдус кызы**

Ул 1964 елның 29 февралендә районыбызның иң гүзәл төбәкләренең берсе Күәм авылында дөньяга килә. Мәктәпкәчә Күәм балалар бакчасында тәрбияләнә. 1971 елның 1 сентябрендә Күәм сигезьеллык мәктәбенең 1 сыйныфына укырга килә. Олы йөрәкле укытучы Гөлсинә апа Шәрипова 27 укучыга ныклы белем һәм тәрбия бирә. Сабыр, тыйнак, укытучы Рузилә Илдус кызында уз һөнәренә мәхәббәт уята. 4 сыйныфтан сыйныф житәкчесе Нурания апа Батталова була. Укытучылары Роза апа Зарипова, Василә апа Кәримова, Илсия апа Хабибуллина, Земфира апа Бургановалар аңа үрнәк булалар. 1979 елда мәктәпне тәмамлаганнан соң, киләчәгее мөгаллимлек һөнәре белән бәйләргә теләп, Арча педагогия училищесына юл тота . Анда 4 ел укып, башлангыч сыйныфларда укыту методикасыннан тирән белем туплап, кулына диплом ала һәм хезмәт юлын тәүге тапкыр 1983 елда Дусым башлангыч мәктәбендә башлап җибәрә.

Тормыш йомгагын сүтә – сүтә, утыз сигез ел үзе сайлаган һөнәрен башкара. Хезмәтемне бик ярата. Укучыларының күңелен аңларга тырышып, кирәк чакта аларга ярдәм кулы сузып эшли. Баштагы елларда бер ук вакытта 3 классны бергә укыта. Бик авыр вакытлар була. Соңыннан 2 класс белән эшли. Аның укучылары тынлаучан, белемгә омтылучан тәртипле булдылар. Алар белән һәр бәйрәмдә авыл клубында концертлар куя иделәр, экиятләр сәхнәләштерделәр. Укуда авыррак булган укучылар да бик теләп катнашалар иде.

Укучыларын яратып, һөнәрен намуслы башкарып, 1994 елда "Өлкән укытучы", 2003 елда " I категорияле укытучы" исеменә лаек була. Тормышының бер минуты да, ягъни бер мизгеле дә шул мәктәп тормышыннан башка үтми. Кайда гына булса да, нәрсә генә эшләсә дә, күңеленә һаман да шул шау – шулы мәктәп тормышы, гөр килеп торган укучылар килә. Аларның һәркайсын барлый. Уңышларына куана.

**Гараева Василә Кәрим кызы** 1950 елда Арча районы Дусым авылында дөньяга килә. Әтисе Кәримулла – колхозчы, әнисе Галия – укытучы. Гаиләдә 6 бала. Мәктәпкәчә әти-әни тәрбиясе алган нәни кызчык 1957 елда Дусым башлангыч мәктәбенә укырга килә. 1960 елдан Күәм сигезьеллык мәткәбендә белем ала. Нәкъ шул елларда Васила күңелендә укытучы булу теләге уяна да инде.

1967/68 уку елында аның күптәнге хыялы тормышка аша, аны Дусым башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгелиләр. Яшь педагог үз хезмәтен чын күңелдән яратып башкара. Балаларга, сайлаган һөнәренә булган мәхәббәте аны Казан педагогия институтына алып килә. 1968 елдан институтның математика бүлегендә белем ала.

1972 елдан Васила Кәримовна Күәм сигезьеллык мәктәбенә математика укытучысы булып билгеләнә. Яшь кызны укытучылар коллективы да, укучылар да үз итә. Ул балалар психологиясен, холкын аңлап, индивидуаль якын килеп, дустанә мөнәсәбәттә намус белән бирелеп эшли. Укытучының эшчәнлеген күреп, 1978 елдан мәктәпнең тәрбия эшләре буенча завучы итеп билгелиләр. Василәнең тырыш хезмәте мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары белән бәяләнә. Аның фотосы күп еллар мәктәпнең мактау тактасында урын ала. 1981 елда ул тормышка чыгып, Казан шәһәренә күчә. Анда да педагогик эшчәнлеген дәвам итеп, балалар бакчасында тәрбияче һәм татар теле укытучысы булып эшли.

388 нче балалар бакчасы коллективы һәм әти-әниләр тарафыннан да олы хөрмәткә лаек педагог була ул. 46 ел хезмәт стажы булган Васила апабыз бүген лаеклы ялда. Үзе кебек тырыш, булдыклы кызлар үстергән апа, бүген инде оныклары белән мәш килә.

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Укытучым**

Дөньяда һөнәрләр бик күп. Һәр кеше һөнәрнең үзенә ошаганын сайларга тиеш. Үзең сайлаган һөнәрнең чын остасы булу өчен бик күп укырга, белемле булырга кешене укытучы өйрәтә.

Мин үземнең беренче укытучым Ганиева Люция апа турында язып китәсем килә. Ул бик яхшы укытучы. Гадел һәм сабыр, тыныч һәм ягымлы. Без аны бик хөрмәт итәбез. Ул безне белемле итү һәм бездә яхшы сыйфатлар тәрбияләү өчен бөтен көчен бирә.

Зур үскәч, минем дә укытучы буласым килә. Укытучы барлык һөнәрләргә дә юл ачучы ул.

**Юсупова Динә, 4нче сыйныф укучысы**

## Олыласаң олыны...

1 нче октябрь көнне, Өлкәннәр көне уңаеннан әбиләрне, дәү әниләрне мәктәпкә очрашуга чакырдык. Алар бик теләп бәйрәмгә килделәр. Очрашу матур узды. Без аларга шигырьләр сөйләдек, сораулар бирдек. Өлкән буын кешеләре күп әйбернең, вакытның, дуслыкның кадерен белергә киңәш иттеләр. Матур теләкләр теләделәр. Үзләре укыган чор турында, эшләре турында сөйләделәр, кул эшләренә осталыкларын күрсәттеләр. Фотографияләрдән карап яшьлекләрен искә алдылар. Бу очрашу безгә дә ошады. Әбиләргә, дәү әниләргә без бик рәхмәтле. Алар безне яраталар, кайгырталар, тәмле ризыклар белән сыйлыйлар. Исән сау булсыннар!

**Нигмазянов Ислам, 6 нчы сыйныф укучысы**



## Иң кадерле кеше ул - әни!

Минем әнием Хәбибуллина Дилә Наил кызы. Хөнәре буенча ул – провизор. Бүгенгесе көндә әнием районыбыз үзәгендә урнашкан дәүләт даруханәсендә (...заместитель заведующего...) булып эшли.

Әнием тәмле ашлар пешерергә, өебезне чиста-пөхтә тотарга бик ярата.

Нечкә күңелле кеше ул. Ләкин кирәк вакытта кырыс та була белә. Ул миңа: "Һәрнәрсәдән дә чыгу юлы бар, нинди генә очракта калсаң да, миннән берни дә яшермә", - дия. Ялганлаганны бер дә яратмый. Ул минем киңәшчем дә, сердәшчем дә. Кичләрен икәү генә утырып чәй эчү инде куптән гадәткә керде. Әни белән шулай сөйләшеп утырырга яратам мин.

Әниене бер кем дә алыштыра алмый. Әниемдә бар дөньяның яме.

**Хәбибуллин Эмил, 5 нче сыйныф укучысы**



## Без –беренчеләр!

24 нче октябрь көнне без 7 нче сыйныф укучылары Садриева Айсинә һәм Халикова Фирүзә, "Алдынгылар хәрәкәте"нең активистлары буларак, Күәм балалар бакчасына бардык. "Туризм һәм сәяхәт" темасына балалар алдында чыгыш ясадык, башкалабыз Казанның тарихи урыннары турында сөйләдек, балаларга сентябрь аенда өләшкән эш дәфтәрләренә шушы теманы яктыртырга ярдәм иттек, алар белән бергә рәхәтләнеп кистек, ябыштырдык, буядык. Казанның истәлекле урыннарын барлагач, үзебезнең Әтнә районы җирлегендәге тарихи биналарны карадык. Балалар белән эшләү күңелле дә, бик җаваплы да!

**Халикова Фирүзә, 7 нче сыйныф укучысы**

## Көтелмәгән якшәмбе

Ура! Бүген якшәмбе! Абый белән йокы туеп уянгач, караватта килеш кенә телефонда уен уйнап ятарга уйладык. Ә нәрсә? Рәхәт бит! Мәктәпкә дә барасы юк! Әмма планнар барып чыкмады.

- Егетләр, торабыз! Тиз-тиз юынып-киенегез, иртәнге ашны ашыйсыз да киттек! – әтинең көр тавышы безне сискәндереп үк җибәрде!
- Ничек? Кая киттек? – диештек без бер авыздан.
- Бүген Ашыт елгасы буена барабыз – табигатькә! Телефоннарны өйдә калдырабыз – гаджетларсыз якшәмбе булачак! – әнинең сүзләре тәмам аптыраштa калдырды.

Нәрсә? Ничек була инде бу? Телефонсыз нишләрбез соң? Ял көненең бер кызыгы калмаячак бит!

Абый миннән хәйләкәррәк булып чыкты:

- Ашыт буен сүрәткә төшерергә телефонны алмыйча булмый! – диде ул, әни пешергән коймакларны авызына тутырып.
- Әлбәттә! Әмма сез сүрәтне телефонсыз гына ясарсыз, - дип серле елмайды әни.

Абый белән моңсу гына бер-беребезгә карашып алдык. Бетте безнең рәхәт якшәмбе!

Без шулай дип уйладык. Әмма хәлләр без уйлаганча килеп чыкмады... Елга буена килеп җиттек тә, телсез калдык! Ашыт үзәне ямь-яшел, елга үзе әллә кайлардан бормаланып-бормаланып килә – елан диярсең! Май уртасы булгангамы, тау битләре шундый матур яшел төстә – бер генә төсле карандаш та, фломастер да мондый матур төсле була алмас! Ә күк! Күк зәп-зәңгәр! Еракта-еракта офыкта нәни генә ак болытлар күренә. Алар күк йөзенә җил күтәргән мамык кисәкләре кебек! Ашыт елгасының биек ярында басып торабыз – йомшак җил безнең чәчләребез белән уйный, якты кояш битләрне сөя – шундый рәхәт!

- Менә, улларым, безнең туган җир нинди матур!

Әнинең сүзләренә әти ризалык биреп баш кагып куйды. Абый белән минем башта берүк уй йөри иде бугай: телефон экранына текәлеп йөрсәң, бу матурлыкны күрми калып та була икән ич!

- Тыңлагыз әле! – диде әти колагын куеп.
- Күк-күк!Күк-күк! Күк-күк!
- Кем кычкыра анда?
- Күке ул! Көннәр жылынганын хәбәр итә! – диде әти безгә күз кысып.

Ул арада әни рюкзагыннан рәсем дәфтәрләре белән төсле карандашлар чыгарды.

- Әйдәгез әле, кем остарак? Табигатьне рәсемгә төшерегез! – диде ул. Без абый белән эшкә керештек. Ап-ак кәгазьгә Ашыт елгасы да, яшел үләнле ярлар да, район үзәгенә сузылган юл да, күк тә, кояш та сыйды! Рәсемнәрне ясап бетерешкә әти белән әни яшел чирәмлеккә табын да корып куйганнар! Термоска әни ясап алып килгән гап-гади чәй дә табигать кочагында бөтенләй

башка төрле тәмле була икән ул! Чәйдән соң рәхәтләнеп уйнадык, сөйләштек, табигатьне күзәттек. Без өйгә кайтканда көн үтеп бара иде инде.

- Менә, егетләр, телефонсыз да көнне күңелле итеп үткәреп була икән!

Әтинең безгә әйткән бу сүзләреннән соң без абый белән бер-беребезгә аптырашып карадык: без бүген телефон турында бөтенләй онытканбыз бит! Күңелсез булыр дигән көнебез шундый күңелле узган, күтәре лмәс дигән кәеф үзеннән-үзе күтәренке булган! Менә сиңа табигать! Менә сиңа якшәмбе!

**Батталов Айрат, 2 нче сыйныф укучысы**

## Туган ягыма алтын көз килде



Сары төс-көз төсе. Сары төс – сагыш төсе, диләр. Сагышлы шул көз. Кояшлы көннәр бакча, парк, урманнар алтынга манчылгандай була. Юкка гына көзне алтын димиләр. Алтын көзгә багышлап күпме шигырьләр, җырлар, картиналар иҗат ителгән. Алтын көз диюгә без табигатьтәге тышкы буяу – бизәкләрне генә күздә тотмыйбыз, әлбәттә. Көзнең алтынлыгы, аның кадерле, барыннан да бигрәк, көзге муллык белән билгеләнә.

Көз башлану белән көннәр кыскалана. Сизелерлек салкынайта. Күк йөзен авыр болытлар каплап ала. Менә иртәдән яңгыр сибәләргә тотына. Кайбер көнне иренеп кенә сибәләгән яңгыр кичкә кадәр туктамый. Салкын җил исә, көн караңгылана. Ә иртән ялт итеп кояш чыга. Күк йөзе шундый зәңгәр, саф! Җир өстенә, ак җәймәдәй булып ап – ак томан сузылып яткан. Салкын. Җәйге төсен җуйган үләннәрдә нечкә боз кисәкләре күренә. Кырау төшкән. Ак томаннар арасыннан, кызыл түгәрәк булып, кояш күтәрелә. Ул үзенең тансык нурлары белән җирне җылытырга тырыша. Акрын гына томан тарала.

Көз көне яктылык та, җылылык та шактый ук кими. Шуңа күрә яфракларның яшеллеге сары, кызгылт- сары, күгелҗем төсләргә алмашына.

Агачлардан усак, миләш, өрәңгенең генә көзге яфраклары кызыл. Калган агачларның яфраклары саргая, ләкин бар да үзенчә: каен яфраклары ачык сары төскә, караманыкы – караңгы сары, имәннеке – саргылт сары, юкәнеке – алтынсу сары төскә керә. Читтән караганда, агачның яфраклары бар да бер төсле күренә. Ә кулыңа алып карасаң – нинди генә төсләр юк монда! Яшел буй – буй сызыклар, көрән таплар, соры бизәкләр. Бар агачлар һәм куаклар, иң матур киемнәрен киеп, көзге бәйрәмгә әзерләнгән сыман. Усал, ачы көзге җил, яфракларны ботакларыннан өзеп алып, әллә кайларга очырып алып китә. Сары, кызыл, көрән, шәмәхә яфраклар, һавада бераз тирбәлеп очканнан соң, җай гына җиргә яталар. Әйтерсең лә җир өстенә сары юрган түшәлгән. Тиздән агачлар ялангач кала.

Көз башында ук күп кенә кошлар төркемнәргә җыела башлыйлар. Аларның көзге сәяхәтләренә вакыт җитә. Берәмләп тә, төркемләп тә, кошлар туган якларыннан, кыш үткәрү өчен, ерак җирләргә очып китә. Кайберләре бик ерак та китми, ә кайберләре меңнәгәнчә километр юл узалар.

Көзнең аяз көннерендә, кыйгач җепкә тезелешеп, торналар очып уза. Сискәндергеч таныш тавышлары бик якында, колак төбендә генә яңгырый кебек, ә үзләре әнә нинди биектә, ак болытларга орынып ук очып баралар. Канатны канатка туры китереп, тигез рәт булып, челәннәр оча. Ә кыр үрдәкләре ерак очышлар вакытында бер – бер артлы тезеләләр, кайчакта аларның сафлары дуга формасында була. Сыерчык, миләш чыпчыгы кебек ваграк кошлар, тәртипсез рәвештә, көтү булып очалар. Мөстәкыйль булып, аерым очкан кошлар да бар.

**Ганиева Зухра, 10 нчы сыйныф укучысы**

## Табигатьнең сихри мизгеле

Табигать һәрвакыт үзгәреп тора. Ел фасыллары алмашынган саен табигать тә яңа киемнәрен кия. Менә хәзерге вакытта да, узенең алтын яфраклары белән, көз килеп житте. Бу ел фасылы, башкаларыннан аеруча матур, урманнар, болыннар үзләренә генә хас бер төскә керәләр. Каеннар иң беренче булып яфракларын коя башлыйлар, ә инде аннан соң калган агачлар да, киемнәрен алыштыралар.

Кырларда комбайннар гөрелтесе ишетелә. Арыш,бодай җирләре бушап кала. Комбайнчылар басуларда көннәр буена, ялны белмичә эшлиләр.Чөнки бер эш көне ел буена туендырачак. Тиздән кырларны кара каргалар яулап ала. Аларның ерак юлга китәр өчен хәл җыясы, тукланасы бар. Алар шунда коелып калган бөртекләрне рәхәтләнеп чүплиләр, аннары, канатларын ныгытыр өчен, төркем-төркем булып очып алалар. Башка кошларда җәй аендагыча сайрамый. Алар ашыгыч игы-зыгыда. Тиздән алар да җылы якларга китеп, кыш беткәнен көтәчәкләр. Зәп-зәңгәр күктә җепкә тезелеп кыр үрдәкләре, торналар саубуллашып, ерак юлга кузгала.

Бакчаларда да күптәннән инде эшләр башланды, һәммәсе дә ,салкын көннәр башланганчы тырышып-тырмашып уңышларын җыялар. Бәрәңгеләрне, суганнарны ,кишерләрне алып бетергәннән соң, бакчаларга тракторлар кереп, бөтен җирләрне сөреп чыгалар. Бу әле авылларда эшләр беткәнне аңлатмый, чөнки бер эш көне ел буена тукландырырга сәләтле.

Көз, аеруча, моңсу ел фасылы. Күбесенчә , ул моңсулыкны, табигатькә төсләр өсти. Кызыл, алтынсу – бу төсләр көзнең аеруча бер үзенчәлеге булып торалар. Урманнарда агачлар, болыннарда үләннәр үзләренә хас булган бер төс алалар. Тиздән салкын көннәр башланып, яңгырлар яварга тотыначак. Ә инде аннан соң, урманнарда, каенлыкларда гөмбәләр баш калкытачаклар, кешеләргә тагын бер эш өстәләчәк кенә.

Көз турында бик күп шигырьләр, җырлар язылган. Бу ел фасылы шагыйрьләргә илһам өстәп

тора. Минем фикеремчә, көз көне, барлык нәрсә дә: кешеләр дә, тереклек тә, кошлар да җанланалар. Кешеләр бакчаларда эшләсәләр, тереклек-җәнлекләр кышка әзерләнәләр, үзләренә азыклар табып, аларны яшереп куялар. Әле көз килгәннән соң да, салкын көннәр булмаячак, чөнки тиздән әбиләр чуагы башлана. Менә шул вакытта инде кешеләр җылы көннәр белән рәхәтләнеп кала алачаклар.

Әә болай, көз бик матур ел фасылы, әле кайчан без шундый матурлык күрә алыр идек? Дөнья шундый төсләргә күмелгән чакта,елмаймыйча булмый. Алтынсу төсләр һәрвакыт күңелләрне генә күтәреп тора.

**Хафизов Ислам, 11 нче сыйныф укучысы**

**Октябрьгә халык сынамышлары: Яфраклар җиргә кире ягы белән ятса, киләсе елга уңыш уңар...**



**1 октябрь** – әгәр бу көнгә торналар җылы якка китеп бетсә, Покрау көнне (14 октябрь) беренче суыкларны көтегез. Әгәр бүген җылы булса, 2 ноябрьгә кадәр көннәр суытмый.
**2 октябрь** – бал кортларын кышка әзерли башлыйлар.
**3октябрь** – бу көнне җил көнчыгыш яки көнбатыштан иссә – яңгырга, көньяк җиле – җылыга, төньяктан искәне – салкынга ишарә.
**4 октябрь** – бүген көн нинди, алдагы 4 атна да шундый булачак.
**5 октябрьдә** каен яфраклары коелып бетмәсә, кар соң ятар.
**6 октябрьдән** чын суык көз – елның өченче фасылы башлана.
**7 октябрьдән** көн сизелерлек кыскара, төннәр караңгы һәм озын.
**8 октябрь** – әгәр бу көнне беренче кар төшсә, 21 ноябрьдә кар ятар.
**9 октябрь** әгәр бүген беренче кар төшсә, ә чия агачында бер генә яфрак та калмаган икән, тиздән кыш җитәр.
**10 октябрьдә** көннәр коры икән, кыш әле тиз генә җитмәс.
**11 октябрьдә** куяннар соры тунын алыштырмый икән, кыш әле килергә ашыкмый. Коры яфраклар җиргә кире ягы белән ята икән, киләсе елга мул ел килер.
**12 октябрьдә** күктә йолдызлар күп булса, кыз коры килер.
**13 октябрь** каен һәм юкә Покрауга кадәр “чишенеп” бетсә, ел уңай килер. Әгәр берән-сәрән яфраклар калса, кыш суык булыр.
Җил көньяктан иссә – кыш җылы булыр. Явым-төшем булмаса, күк йөзе чиста икән, тиздән суытыр.
**16 октябрь** – соры болытлар түбән йөзә икән, көн бозылыр.
**17 октябрь** – җил тынса – көннәр суытыр.
**18 октябрь** – әгәр ала каргалар һәм чәүкәләр һавада очып уйный, ә болытлар җилгә каршы йөзә икән, кар явар.
**19 октябрь** – коры кар төшкәләсә, киләсе ел җәе җылы, уңыш мул булыр.
**20 октябрь** – агачта яфраклар коелып бетмичә, кар яуса, тиздән эреп бетәр.
**21 октябрь** болытлар җиргә салынып торса, тиздән суытыр.
**22 октябрь** түбәләрдә боз сөңгеләре күренсә – көз китәргә ашыкмый дигән сүз.
**23 октябрь** көнне айны күзәтәләр. Әгәр “мөгезе” төньякка карап тора икән, тиздән суыклар җитәр. Көньякка караса – бер атна җылы торыр. Көнчыгыш яки көнбатышка юнәлсә – көчле суык җил көтегез.
**24 октябрь** иртән кар очса, кыш суык килер.
**25 октябрьдә** йолдызларга карыйлар. Алар якты яналар икән – суыта, тоник икән – җепшек карга, зәңгәр төсмер белән балкып янсалар – кар көтегез. Балкучы йолдызлар бик күп икән, киләсе елга борчак уңар.

**Бу кызыклы...**

Күбәләкләр азыкның тәмен аяклары белән белә.
Кайбер күбәләкләр зур кешенең учы кадәр зурлыкта үсә ала.
Бал кортының, ашказанынннан тыш, бал җыю өчен аерым урыны бар.
Энә карагы төрле юнәлештә оча ала: алга, артка һәм як-якка.
Тарантул үрмәкүче 2 ел азыксыз тора ала.
Ирландия, Исландия, Гренландия һәм Антарктидада еланнар юк.
Чаян караңгыда яктырып күренә.
Күселәрне кытыкласаң, алар көлә ала.
Сукыр тычкан төн эчендә 300 метр озынлыктагы тоннель казый ала.
Мәчесыманнар семьялыгыннан булган оцелотлар бик яхшы йөзә.
Басенджи токымлы этләр бөтенләй өрми.
Теле ал төстә булмаган бердәнбер эт – чау-чау.
Атларның хәтере яхшы. Алар кешеләрне, әйберләрне, шулай ук кайчандыр белгән һөнәрләрен истә калдыра.
Сыерныкына караганда кәҗә сөтендә май 5 тапкыр кимрәк. Сыер сөте – 1 сәгать, кәҗәнеке 20 минут үзләштерелә.
Тавык елга уртача 190 йомырка сала.
Пошиның мөгезләре бик сизгер.

**Гәҗитне басмага әзерләделәр**

**Баш мөхәррир: Сөнгатова Г.З.**
**8 нче сыйныф укучысы :Шакирова Камилә.**
**6 нчы сыйныф укучысы: Галявиева Алия.**
**10 нчы сыйныф укучысы:Гатауллина Илүзә.**